**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Положение об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан**

В связи с изменениями в федеральном законодательстве в области гражданской обороны **постановляю:**

1. Внести в Положение об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан, утвержденное Указом Президента Республики Татарстан от 22 ноября 2008 года № УП-598 «Об утверждении Положения об организации и ведении гражданской обороны в Республике Татарстан» (с изменениями, внесенными Указом Президента Республики Татарстан от 17 октября 2014 года № УП-995), следующие изменения:

а) абзац седьмой пункта 2.3 после слов «выполнения мероприятий» дополнить словами «регионального уровня»;

б) в пункте 2.4:

в абзаце четвертом слова «и обучение» исключить;

в абзацах пятом и девятом слова «при ведении военных действий или вследствие этих действий» заменить словами «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов»;

в) в абзаце первом пункта 3.1 слово «обучению» заменить словом «подготовке»;

г) в пункте 3.2:

в абзаце первом слова «при ведении военных действий или вследствие этих действий» заменить словами «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов»;

в абзаце втором слова «оповещения населения в постоянной готовности» заменить словами «оповещения населения»;

д) в абзаце третьем пункта 3.3 слова «подготовка районов» заменить словами «подготовка безопасных районов для»;

е) в пункте 3.4:

в абзаце первом слова «убежищ и средств индивидуальной защиты» заменить словами «средств индивидуальной и коллективной защиты»;

абзацы третий и четвертый изложить в следующей редакции:

«приспособление в мирное время и при приведении гражданской обороны в готовность к ее ведению и в ходе ее ведения в военное время

заглубленных помещений и других сооружений подземного пространства для укрытия населения;

подготовка в мирное время и строительство при приведении гражданской обороны в готовность к ее ведению и в ходе ее ведения в военное время быстровозводимых защитных сооружений гражданской обороны с упрощенным внутренним оборудованием и укрытий простейшего типа;»;

ж) в пункте 3.5:

абзац первый после слова «световой» дополнить словом «маскировке»;

абзац второй изложить в следующей редакции:

«создание и поддержание организациями, отнесенными в установленном порядке к категориям по гражданской обороне, и организациями, обеспечивающими выполнение мероприятий по гражданской обороне, в состоянии постоянной готовности к использованию по предназначению запасов материально-технических средств, необходимых для проведения мероприятий по световой маскировке и другим видам маскировки;»;

з) в пункте 3.6:

абзац первый изложить в следующей редакции:

«3.6. По проведению аварийно-спасательных и других неотложных работ в случае возникновения опасности для населения при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также вследствие чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера и террористических актов:»;

дополнить абзацем следующего содержания:

«учет и ведение реестров нештатных аварийно-спасательных формирований, привлекаемых для решения задач в области гражданской обороны, и нештатных формирований по обеспечению выполнения мероприятий по гражданской обороне.»;

и) в пункте 3.7:

абзац первый изложить в следующей редакции:

«3.7. По первоочередному жизнеобеспечению населения, пострадавшего при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера:»;

в абзаце шестом слова «при ведении военных действий или вследствие этих действий» заменить словами «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов»;

к) в абзаце первом пункта 3.8 слова «при ведении военных действий или вследствие этих действий» заменить словами «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов»;

л) в пункте 3.9:

в абзаце первом слова «и иному заражению (загрязнению)» заменить словами «или иному заражению»;

в абзаце третьем слово «загрязнению» заменить словами «заражению (загрязнению)»;

м) в абзаце первом пункта 3.11 слова «при ведении военных действий или вследствие этих действий» заменить словами «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов»;

н) абзац первый пункта 3.14 изложить в следующей редакции:

«3.14. По обеспечению устойчивости функционирования организаций, необходимых для выживания населения при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов, а также при чрезвычайных ситуациях природного и техногенного характера:»;

о) в абзаце третьем пункта 4.13 слова «при ведении военных действий или вследствие этих действий» заменить словами «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов»;

п) в абзаце первом пункта 4.17 слова «при ведении военных действий или вследствие этих действий» заменить словами «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов»;

р) абзац второй пункта 4.18 изложить в следующей редакции:

«Сбор информации и обмен ею осуществляются органами исполнительной власти Республики Татарстан, органами местного самоуправления и организациями, эксплуатирующими опасные производственные объекты I и II классов опасности, особо радиационно опасные и ядерно опасные производства и объекты, гидротехнические сооружения чрезвычайно высокой опасности и гидротехнические сооружения высокой опасности, а также организациями, отнесенными в установленном порядке к категориям по гражданской обороне.»;

с) в пункте 5.1 слова «при ведении военных действий или вследствие этих действий» заменить словами «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов»;

т) в пункте 5.2 слова «при ведении военных действий или вследствие этих действий» заменить словами «при военных конфликтах или вследствие этих конфликтов»;

у) пункт 5.3 изложить в следующей редакции:

«5.3. Планы гражданской обороны и защиты населения (планы гражданской обороны) определяют объем, организацию, порядок обеспечения, способы и сроки выполнения мероприятий по гражданской обороне и ликвидации чрезвычайных ситуаций.».

2. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
19 января 2016 года
№ УП-18

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Граждан оборонасы өлкәсендә федераль законнарга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2.3 пунктның җиденче абзацында «һәм граждан оборонасы буенча» сүзләреннән соң «төбәк дәрәҗәсендәге» сүзләрен өстәргә;

б) 2.4 пунктта:

дүртенче абзацта «һәм өйрәтүне» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче һәм тугызынчы абзацларда «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3.1 пунктның беренче абзацында «өйрәтү» сүзен «әзерләү» сүзенә алмаштырырга;

г) 3.2 пунктта:

беренче абзацта «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «халыкка хәбәр итү системасын даими әзерлектә тоту» сүзләрен «халыкка хәбәр итү» сүзләренә алмаштырырга;

д) 3.3 пунктның өченче абзацында «районнарын» сүзләрен «өчен куркынычсыз районнар» сүзләренә алмаштырырга;

е) 3.4 пунктта:

беренче абзацта «яшеренү урыннары һәм индивидуаль саклану чаралары» сүзләрен «шәхси һәм күмәк саклану чаралары» сүзләренә алмаштырырга;

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«тыныч вакытта һәм граждан оборонасын алып бару өчен әзерлек хәленә китергәндә һәм сугыш вакытында аны алып барганда халыкка ышерену өчен тирәнәйтелгән урыннарны һәм җир астындагы мәйданнарның башка корылмаларын яраклаштыру;

граждан оборонасының тиз корыла торган гади эчке җиһазлы саклану корылмаларын һәм иң гади типтагы ышерену урыннарын тыныч вакытта әзерләү һәм граждан оборонасын алып бару өчен әзерлек хәленә китергәндә һәм сугыш вакытында аны алып барганда төзү;»;

ж) 3.5 пунктта:

беренче абзацта «яктылык» сүзеннән соң «маскировкалау» сүзен өстәргә;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Билгеләнгән тәртиптә граждан оборонасы категорияләренә кертелгән оешмалар һәм граждан оборонасы буенча чаралар үтәлүен тәэмин итүче оешмалар тарафыннан яктылык маскировкалау һәм маскировкалауның башка төрләре буенча чаралар күрү өчен матди-техник кирәк-яраклар запасын булдыру һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту;»;

з) 3.6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык актлары нәтиҗәсендә халыкка куркыныч янаган очракта һәлакәттән коткару эшләре һәм кичектергесез башка эшләр башкару буенча:»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«һәлакәттән коткару буенча граждан оборонасы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җәлеп ителә торган штаттан тыш формированиеләрне һәм граждан оборонасы буенча чаралар үтәлүен тәэмин итә торган штаттан тыш формированиеләрне исәпкә алу һәм реестрларын алып бару.»;

и) 3.7 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкның тормыш эшчәнлеген беренче чиратта тәэмин итү буенча:»;

алтынчы абзацта «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

к) 3.8 пунктның беренче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

л) 3.9 пунктта:

беренче абзацта «һәм башка зарарлануга (пычрануга)» сүзләрен «яки

башка зарарлануга» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «пычрануга» сүзен «зарарлануга (пычрануга)» сүзләренә алмаштырырга;

м) 3.11 пунктның беренче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

н) 3.14 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.14. Хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның тереклеге өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү буенча:»;

о) 4.13 пунктның өченче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

п) 4.17 пунктның беренче абзацында «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

р) 4.18 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгълүмат туплау һәм аның белән уртаклашу Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм куркынычлык дәрәҗәсе I һәм II класслы җитештерү объектларын, нурланыш куркынычы аеруча югары һәм атом-төш куркынычы булган производстволарны һәм объектларны, куркынычлык дәрәҗәсе гаять югары булган гидротехник корылмаларны һәм куркынычлык дәрәҗәсе югары булган гидротехник корылмаларны эшләтүче оешмалар, шулай ук билгеләнгән тәртиптә граждан оборонасы категорияләренә кертелгән оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

с) 5.1 пунктта «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

т) 5.2 пунктта «хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә әлеге хәрәкәтләр нәтиҗәсендә» сүзләрен «хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

у) 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Граждан оборонасы һәм халыкны саклау планнары (граждан оборонасы планнары) граждан оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чараларны тәэмин итүнең күләмен, оештырылуын, тәртибен, чаралар башкаруның ысулларын һәм вакытларын билгели».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 19 гыйнвар
№ ПУ-18